**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «23» октябреннән №49-373

2024 елда Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә мәдәният, сәнгать һәм музей эше үсешенең төп юнәлешләре һәм 2025 елга бурычлар турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге начальнигы Г.А.Носованың 2024 елда Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә мәдәният, сәнгать һәм музей эше үсешенең төп юнәлешләре һәм 2025 елга бурычлар турында мәгълүмат тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге начальнигы Г.А.Носованың 2024 елда Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә мәдәният, сәнгать һәм музей эше үсешенең төп юнәлешләре һәм 2025 елга бурычлар турында мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлегенә:

- дәүләт бәйрәмнәренә, хәрби дан көннәренә, Россия халыклары тарихында юбилей һәм истәлекле даталарга, 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына һәм Татарстан Республикасында Ватанны саклаучылар елына багышланган тантаналы чаралар үткәрүгә ярдәм итәргә;

- халык сәнгате һөнәрләрен, декоратив-гамәли иҗатын саклау һәм үстерү чаралары (фестивальләр, күргәзмәләр, ярминкәләр һ.б.) үткәрүне дәвам итәргә;

- мәдәният учреждениеләренең иҗади һәм җитәкче хезмәткәрләр өчен квалификацияләрен күтәрү һәм һөнәри яктан яңадан әзерләү курсларын оештыру аша мәдәният тармагы өчен кадрлар әзерләүне дәвам итәргә;

- муниципаль мәдәният учреждениеләренең иҗат коллективларына ярдәм итү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларында катнашуны активлаштырырга;

- авыл җирлекләре территорияләрендәге капиталь ремонт таләп итүче мәдәният учреждениеләрен реконструкцияләүне дәвам итәргә.

- мәдәният учреждениеләренең «Пушкин картасы» программасы буенча эшен көчәйтергә һәм вакыйгаларны PRO.Культура.РФ сайтында урнаштырырга.

3. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клублар системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенә:

- халык иҗатын үстерү, үзешчән коллективлар булдыру, яңа йолаларны, гореф-гадәтләрне торгызу буенча чаралар күрергә;

- район конкурслары, халык иҗаты фестивальләре үткәрергә;

- районның мәдәни-ял учреждениеләрендә клуб оешмалары һәм һәвәскәрләр берләшмәләре санын арттырырга;

- районның кече торак пунктларында иң яхшы иҗат коллективларының концерт эшчәнлеген дәвам итәргә;

- матди булмаган мәдәни мирасны саклау эшен дәвам итәргә.

4. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә Балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенә:

- музыкаль сәнгать өлкәсендә талантлы яшьләргә этәргеч бирергә;

- балалар сәнгать мәктәбен кирәкле кораллар, җиһазлар һәм материаллар белән тәэмин итәргә.

5. «М.Газыймов исемендәе Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы халык иҗаты һәм көнкүреше музее» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенә, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенә:

- районның торак пунктларыннан 1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында катнашкан һәр кешегә, Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итү кысаларында хәтерне мәңгеләштерү максатыннан, Россия Федерациясе авыллары һәм муниципаль берәмлекләре хәтеренең электрон китабына кертү өчен, материал җыюны тәгәлләргә;

- Мирхәйдәр Фәйзи исемендәге Шахмай авылы тарихы музеен җиһазландыруга «Татнефть» ГАҖнең БФ грант конкурсында катнашу өчен «Хәтер сакчысын торгызу» проектын әзерләргә.

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга. http://novosheshminsk.tatarstan.ru

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов